| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>АГРЫЗСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.09.2020 г. Агрыз № 1-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең үз теләге белән вәкаләтләре туктатылу турында

Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Вәлиев Азат Рөстәм улының «16 нчы бермандатлы Әгерҗе сайлау округы буенча «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы депутаты итеп сайлануга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең үз теләге белән эшләгән вазыйфасыннан вакытыннан алда азат итү турында» гаризасын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә (2020 елның 06 мартына үзгәрешләр һәм өстәмәләр исәпкә алып), Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Вәлиев Азат Рөстәм улының үз теләге белән язылган гаризасын кабул итәргә һәм контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең вәкаләтләрен 2020 елның 14 сентябреннән туктатырга.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Вәлиев Азат Рөстәм улы белән 2020 елның 14 сентябреннән контрактны туктатырга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Советы утырышында рәислек итүче,
5 нче Кадыбаш сайлау округы буенча
Кадыбаш авыл җирлеге депутаты И.Г. Рамазанов